ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.04.2022 г.Лениногорск № 9

2022 елның беренче яртыеллыгында Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетыннан Лениногорск шәһәре урамнарыннан, шул исәптән юл өлешен, юл чатларын, җәяүлеләр өчен чыгу юлларын һәм тротуарларны да кертеп кар чистарткан һәм чыгарган өчен чыгымнарның бер өлешен каплау өчен оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы (2021 елның 30 сентябрендәге ред.) карары нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясенең 2022 елның 15 мартындагы 6-22 номерлы «Лениногорск шәһәре урамнарын кардан һәм боздан чистарту чаралары турында» күрсәтмәсе нигезендә, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның беренче яртыеллыгында Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетыннан Лениногорск шәһәре урамнарыннан, шул исәптән юл өлешен, юл чатларын, җәяүлеләр өчен чыгу юлларын һәм тротуарларны да кертеп кар чистарткан һәм чыгарган өчен чыгымнарның бер өлешен каплау өчен оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турында кушымта итеп бирелгән нигезләмәне расларга.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» МКУ субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотарга.

3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Р. Сытдиков

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72